**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 29 гыйнварындагы 151 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 15 мартындагы 762 номерлы «Вахитов районының Профсоюз урамындагы җир кишәрлекләре өлешләренә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Казан электр челтәрләре – «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте филиалының Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 15 мартындагы 762 номерлы «Вахитов районының Профсоюз урамындагы җир кишәрлекләре өлешләренә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакындагы гаризасы нигезендә, 2001 елның 25 ноябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.6 статьясына, Россия Федерациясе Җир кодексының V. 7 бүлегенә таянып **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 15 мартындагы 762 номерлы «Вахитов районының Профсоюз урамындагы җир кишәрлекләре өлешләренә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктын гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. 7.1 һәм 7.2 пунктчаларын гамәлдән чыккан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**